Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге
Күн авылының М.Конов, Комсомол урамнарында яшәүче гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

15 октябрь, 2024 ел № 3

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлегенең Күн авылының М.Конов, Комсомол урамнарында яшәүче гражданнарның 2024 елның 15 октябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 89 (сиксән тугыз).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 52 (илле ике).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 51 (илле бер).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2025 елда Күн авылының М.Конов, Комсомол урамнарында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы студентларын, 90 яшьтән өлкәнрәк кешеләрне, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен җиһазлар тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау;
- урамнарны яктырту җайланмасы;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү (авария хәлендәге агачларны кисү)» **кабул ителгән дип санарга**.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Күн авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Күн авыл җирлеге башлыгы Р. Г. Баһауов